| Республика Татарстан | | Татарстан Республикасы |
| --- | --- | --- |
| СОВЕТ САБИНСКОГО ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САБА ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ — КАРАР

25 апрель 2024 ел — №9

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы тарафыннан 25.01.2021 елгы №2 “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында”гы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 12.12.2023 елгы № 594-ФЗ Федераль закон нигезендә һәм Саба районы Прокуратурасының 16.04.2024 елгы №02-08-02-2024/Прдп192-24-20920031 протестын карап, Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советы тарафыннан “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәне раслау хакында”гы 25.02.2021 №2 карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 13.4 пунктны "мәгълүмат" сүзеннән соң «(анкетада булган мәгълүматлардан тыш)» сүзләре белән тулыландырырга;

1.2. 25.1 пунктның 11) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11) Муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны үткән вакытта гражданин тарафыннан бирелә торган мәгълүматларны тикшерүне оештыру һәм үткәрү;";

1.3. 25.1 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 15) пунктча белән тулыландырырга:

"15) Дәүләт серен тәшкил итүче мәгълүматка билгеләнгән формадагы рөхсәтне рәсмиләштерү.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге http://pravo.tatarstan.ru/saba адресы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен тәэмин итүне үз өстемә алам.

Җирлек башлыгы Р.М. Хәсәнов